**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

чираттан тыш утырыш

20 октябрь 2020 ел №10 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2020 елның 23 сентябрендәге №8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 10 октябрендәге ПУ-679 номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш кертү турында» Указы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 23 сентябрендәге №8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составыннан Хәсәнов Айрат Рәшад улын - Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләр эшчәнлеген һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең оештыру эшен тәэмин итү бүлегенең төп киңәшчесен чыгарырга (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс

комиссиясе составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Салихов Ирек Фәрит улын кертергә (килешү буенча).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары -
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Советы
рәисе урынбасары З.В. Ильясов